**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ МОРДОВСКО-АФОНЬКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423103, Мордовское Афонькино село, Цаплина ул., 19 дом

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**МОРДВА АФОНЬКӘСЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423103, Мордва Афонькәсе авылы, Цаплин урамы, 19нче йорт

тел. (84396) 3-48-29, факс: (84396) 3-48-49, email: Mord.Cmn2@tatar.ru

№39 30.09.2021ел

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының 2013 елның 12 февралендәге 55 номерлы «Чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында таләпләрне һәм коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен түләтүләрне куллану тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25 номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының 2013 елның 12 февралендәге 55 номерлы «Чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында таләпләрне һәм коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен түләтүләрне куллану тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» карарына (2018 елның 21 декабрендәге 101 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «Дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25 номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Мордва Афонькәсе авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе — А.И.Митяев